КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 14 апрель г.Казань № 474

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә сайлауларны әзерләү һәм үткәрүне оештыруда сайлау комиссияләренә булышлык күрсәтү турында» 2017 ел, 30 ноябрь, 932 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә сайлауларны әзерләү һәм үткәрүне оештыруда сайлау комиссияләренә булышлык күрсәтү турында» 2017 ел, 30 ноябрь, 932 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 30 март, 196 нчы, 2019 ел, 29 апрель, 353 нче, 2019 ел, 8 ноябрь, 1026 нчы, 2020 ел, 23 сентябрь, 862 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктта татар текстында «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә сайлауларны әзерләү һәм үткәрүне оештыруда сайлау комиссияләренә булышлык күрсәтү буенча эшче төркем составында:

эшче төркем составыннан М.Н.Садыйковны, А.М.Терентьевны чыгарырга;

эшче төркем составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Миңнуллин Марсель Мансур улын | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрын |

| | |
|---|---|
| Мөхәрләмов Руслан Роберт улын | Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесен (килешү буенча); |

Лилия Камил кызы Галимованың вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе Матбугат хезмәте җитәкчесе (килешү буенча)»;

Гарипов Илнур Мәхмүт улы вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенең беренче урынбасарын – Татарстан Республикасы Рәисенең Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгын (килешү буенча)»;

Глухова Лариса Юрьевна вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт-хокук идарәсе башлыгын (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин